Республика Татарстан
**СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ПОСЕЛОК ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ» САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**
Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

РЕШЕНИЕ
06.05.2021 ел

КАРАР
№33

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 27 февралендәге 27-ФЗ номерлы Федераль закон (2020 елның 1 апреленә үзгәрешләр кертелде) нигезендә, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 24 апрелендәге 148-ФЗ номерлы Федераль закон», «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 20 июлендәге 236-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 31 июлендәге 263-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 46 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 9 ноябрендәге 363-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында Федераль законга һәм Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 8 декабрендәге 411-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 464-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге 518-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставының 89-90 статьялары

белән, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2015 елның 17 декабрендәге 18 номерлы карары нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгына «Муниципаль берәмлекләрнең уставларын дәүләт теркәве турында»гы 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны дәүләт теркәвенә алуны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар, әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 1 өлешеннән һәм 7 өлешнең 7.3 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә. Әлеге карарның 1 нче кушымтасындагы 1 өлеш һәм 7 өлешнең 7.3 пункты 2021 елның 29 июненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы Рәисе Р.Ә. Кәримов

2021 елның 6 май 33 номерлы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы карарына1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе
_____________________ Р.Ә. Кәримов

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советының 2015 елның 17 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

1. 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 40 пункт өстәргә:

«40) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек әобъектларына хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм чаралар үткәрү, күчемсез милек объектларының хокук ияләре турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү.»

2. 8 статьяда:

2.1. 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16) полиция участок уполномоченные вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына хезмәткәр тарафыннан күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында торак урыны бирү;»

2.2. 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17) алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру;»

3. 19 статьяда:

3.1. 9 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 7 пункт өстәргә:

«7) инициативалы проектны тикшерү һәм аны хуплау турындагы мәсьәлә буенча карар кабул итү;»

3.2. Түбәндәге эчтәлекле 10.1 өлеш өстәргә:

«10.1. Территориаль иҗтимагый үзидарә органнары инициативалы проектны проект инициаторлары сыйфатында тәкъдим итә алалар;»

4. 21 статьяда:

4.1. 1 пунктта «җирлекнең җирле үзидарә вазыйфаи затларын билгеләү» сүзләреннән соң «инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча фикер алышу» сүзләрен өстәргә.

4.2. 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инициативалы проектларны кертү һәм аларны карау мәсьәләләре буенча гражданнар җыелышында уналтынчы яшькә җиткән Тиешле территориядә яшәүчеләр катнашырга хокуклы. Инициативалы проектларны кертү мәсьәләләрен

карау һәм тикшерү максатларында гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе җирлек Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә;»

5. 23 статьяда:

5.1. 2 өлешне түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән тулыландырырга: «гражданнарның инициативалы проектка ярдәм итү турындагы фикерләрен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелгән сораштыруда унтугыз яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителгән җирлек яки аның бер өлешендә яшәүчеләр катнашырга хокуклы;»

5.2. 3 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

«3) унтугыз яшькә җиткән инициативалы проектны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә торган җирлек халкы яисә аның бер өлеше - әлеге инициативалы проектка ярдәм итү турында гражданнарның фикерен ачыклау өчен;»

5.3. 5 өлешнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны сораштыру билгеләү турында карар җирлек Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнар арасында сораштыру үткәрү өчен Сарман муниципаль районының рәсми сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча файдаланырга мөмкин: sarmanovo.tatarstan.ru. Авыл җирлеге Советының гражданнарның сораштыру билгеләү турында норматив хокукый актында билгеләнә:»

5.4. 5 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районы рәсми сайтыннан файдаланып, гражданнар арасында сораштыру уздырган очракта, сораштыруда катнашучыларны идентификацияләү тәртибе: sarmanovo.tatarstan.ru»;

5.5. 7 өлешнең 1 пунктчасына «җирлек халкы өчен» сүзләрен өстәргә.

6. 29 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Җирлек Советы депутатына үз вәкаләтләрен даими рәвештә гамәлгә ашыру өчен, айга дүрт эш көне чорында эш урынын (вазыйфасын) саклау гарантияләнә».

7. 47 статьяда:

7.1. 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

17) полиция участок хезмәткәре вазыйфасын биләгән хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына күрсәтелгән вазыйфаны хезмәткәр биләгән чорда торак урыны бирә»;

7.2. 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

«18) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра».

7.3. 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19) җирлек территориясендә элек исәпкә алынган күчемсез милек объектларына хокук ияләрен ачыклау буенча чаралар күрү һәм үткәрү, күчемсез милек объектларының әлеге хокук ияләре турында мәгълүматларны Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрына кертү өчен җибәрү;»

8. 69 статьяның 3 өлешен түбәндәге редакциядә укырга:

«3. Җирлек Советының элек җирлек Советының норматив хокукый актларында каралган эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен вазыйфаларны билгели торган яңа яисә үзгәртә торган норматив хокукый актлары проектлары,

Татарстан Республикасы Законы нигезендә, җирлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан үткәрелә торган җайга салу йогынтысын бәяләргә мөмкин, моннан тыш:

1) җирлек Советының җирле салымнар һәм җыемнар билгели, үзгәртә, туктатып тора, юкка чыгара торган норматив хокукый актлары проектлары;;

2) җирлек Советының бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы норматив хокукый актлары проектлары;

3) Гадәттән тыш хәлләр режимнары гамәлдә булган чорда табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү максатларында эшләнгән норматив хокукый актлар проектлары.

Муниципаль норматив хокукый актлар проектларының җайга салу йогынтысын бәяләү эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектлары өчен артык вазыйфалар, тыюлар һәм чикләүләр кертә торган яисә аларны кертүгә этәрә торган нигезләмәләрне, шулай ук эшкуарлык һәм инвестиция эшчәнлеге субъектларының һәм җирле бюджетларның нигезсез чыгымнары барлыкка килүгә ярдәм итә торган нигезләмәләрне ачыклау максатларында үткәрелә.»

9. 81 статьяның 3 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

10. 91 статьяның 2 өлешендә «аның» сүзен төшереп калдырырга, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 6 өлешендә каралган Татарстан Республикасы, җирлек уставы, җирлек Советы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында хәбәрнамәләр Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре уставларын дәүләт реестрына кертү» сүзләрен өстәргә.